ГОСУДАРСТВЕННЫЙ
КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

г.Казань

22.04.2014 № 1

**Татарстан Республикасы Туризм буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куелганда гражданнар үз керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре урында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле, шулай ук дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында**

“Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куелганда гражданнар һәм дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле вазыйфалары исемлеген раслау турында” 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы һәм “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре биләгәндә үз чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында” 2013 елның 22 апрелендәге ПУ-329 номерлы Татарстан Республикасы Президенты указлары нигезендә **боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Туризм буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куелганда гражданнар үз керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре урында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле, шулай ук дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук

хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген алга таба – Исемлек) расларга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Татарстан Республикасы Туризм буенча дәүләт комитетында (алга таба – Дәүләт комитеты) Исемлеккә кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфасын (алга таба – дәүләт хезмәте вазыйфасы) биләгән, граждан, әгәр әлеге оешма дәүләт идарәсенең аерым функцияләре Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең Дәүләт комитетындагы вазыйфаи (хезмәттәге) таләпләренә кергән булса, Татарстан Республикасы Туризм буенча дәүләт комитетында Хезмәт итү тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе ризалыгы белән, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән (алга таба – дәүләт хезмәте) азат ителгәннән соң ике ел эчендә хезмәт шарнамәсе шартларында оешмада вазыйфа биләргә һәм (яисә) әлеге оешмага бер ай дәвамында граждан-хокук шартнамәсе (граждан-хокук шартнамәләре) шартларында йөз мең сумнан артык күләмдәге эш башкарырга хокуклы.

2.2. Татарстан Республикасы Туризм буенча дәүләт комитетында Исемлеккә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан дәүләт граждан хезмәтеннән азат ителгәннән соң ике ел эчендә әлеге пунктның 2.1 пунктчасында күрсәтелгән эшләр башкару (хезмәтләр күрсәтү) турындагы граждан-хокук шартнамәләрен имзалаганда эш бирүчегә үзенең соңгы хезмәт итү урыны турындагы белешмәләрне хәбәр итәргә тиеш.

2.3. Дәүләт комитетында Исемлеккә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданның дәүләт хезмәтеннән азат ителгәннән соң әлеге пунктның 2.2 пунктчасында каралган таләпне үтәмәве әлеге граждан белән төзелгән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яисә граждан-хокук шартнамәсен өзүгә китерә.

3. Кадрлар һәм юридик эш секторы (Таҗетдинова З.Ф.) түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

3.1. Әлеге боерык белән Дәүләт комитетында Исемлеккә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләрен таныштырырга тиеш.

3.2. Исемлекне Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына һәм Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә расланганнан соң өч көн эчендә тапшырырга, соңыннан аңа үзгәрешләр керткәндә төгәлләштерелгән Исемлекне үзгәрешләр кертелгәннән соң бер атна эчендә тапшырырга тиеш.

4. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

**Рәис** **С.Е.Иванов**

Татарстан Республикасы Туризм
буенча дәүләт комитетының
22.042014 елның № 1
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Туризм буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куелганда гражданнар үз керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре урында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле, шулай ук дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Татарстан Республикасы Туризм буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары.
2. Туризм эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу бүлеге башлыгы.
3. Туризм продуктын адга сөрү бүлеге башлыгы.
4. Туризм индустриясен үстерү бүлеге башлыгы.
5. Дәүләт программаларын үстерү һәм гамәлгә ашыру бүлеге башлыгы .
6. Бухгалтер исәпкә алуы һәм дәүләт заказы бүлеге башлыгы.
7. Кадрлар һәм юридик эш секторы мөдире.
8. Туризм эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу бүлегенең әйдәүче киңәшчесе.
9. Кадрлар һәм юридик эш секторының әйдәүче киңәшчесе.
10. Кадрлар һәм юридик эш секторының әйдәүче консультанты.
11. Бухгалтер исәпкә алуы һәм дәүләт заказы бүлегенең әйдәүче белгече.
12. Бухгалтер исәпкә алуы һәм дәүләт заказы бүлегенең 1 нче разрядлы өлкән белгече.

___